ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

«21» декабрь 2021 ел № 429

2021-2022 уку елына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында яңа мәктәп автобус маршрутларын раслау турында

«Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 03 августындагы 615 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, яңа мәктәп автобус маршрутлары ачылуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укучыларын расланган маршрутлар буенча балалар китерү өчен махсус җайлаштырылган автобуслар белән даими һәм куркынычсыз тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021-2022 уку елына мәктәп маршрутларын расларга:

- № 18 «Нариман ур., 27 (ТР Әгерҗе муниципаль районының Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясе МБМУ) – Чапаев ур – Сәетов ур - Карл Маркс ур - Заводская, 43 (тукталыш) - Карл Маркс ур. – Сәетов ур – Нариман ур, 27»;

- № 19 «Нариман ур., 27 (ТР Әгерҗе муниципаль районының Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясе МБМУ) – Чапаев ур – Сәетов ур - Карл Маркс ур - Агрызская, 21а (тукталыш) – Карл Маркс ур.- Сәетов ур. - Нариман, 27»;

- № 20 «Нариман ур., 27 (ТР Әгерҗе муниципаль районының Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясе МБМУ) - Чапаев ур – Сәетов ур - Карл Маркс ур 109 (тукталыш) -Шабалин ур. (тукталыш) - Карл Маркс ур.– Сәетов ур - Нариман, 27».

2. 2021-2022 уку елына әлеге карарның 1 п.1 пунктында күрсәтелгән мәктәп маршрутлары буенча автобус хәрәкәтен рөхсәт итәргә.

3. «Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә тәкъдим итәргә»:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 03 августындагы 615 номерлы карары белән расланган Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы нигезләмә таләпләре нигезендә мәктәп автобуслары маршрутлары паспортын әзерләргә, килештерергә һәм расларга;

- мәктәп автобус маршрутлары реестрына тиешле үзгәрешләр кертергә;

- автобус хәрәкәтенең дәрес һәм дәрестән тыш вакытта графигын әзерләргә һәм ел саен аныкларга;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлеге ЮХИДИ бүлеге белән килештереп, укучыларны утырту һәм төшереп калдыру пунктын билгеләргә.

4. Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә балаларны уку урынына китергәндә һәм кире алып кайтканда озату өчен җаваплы башкаручыларны билгеләргә.

5. Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән расланган мәктәп маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда укучыларның иминлеген тикшереп торуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

Җитәкчесе **А.Э. Акбашев**